

Чаян

СКОРПИОН

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * ГЫЙНВАР * 2016 КАЗАН

1

ISSN 0136-7110



Виталий ПОДВИЦКИЙ

АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Гейлар Европа хатын-кызларын якларга әзерләр. Алар мигрантлар да була торган митингларга шул гүзәл затлар урынына чыгачаклар.
- Сәламәтлек саклау министрлыгы фаразлый: пенсиягә чыгу яшен арттыру рәсәйлеләрнең чамадан тыш яшәрүенә китерәчәк.
- СТС телеканалында “Мин ничек урыс булдым” дигән яңа сериал башланачак. Баш рольләрдә Жерар Депардье һәм Рой Джонс.
- Төрек отельләре хуҗалары, урыслардан башка немец туристлары бөтенләй курку дигән нәрсәне югалтачаклар дип куркалар.
- Бер кешене, президентның рекордлы рейтингы хакында шик белдерүе сәбәпле, ышаныч баглаучыларның мәнфәгатенә каршы килүенә сылтау ясап, хөкем итәләр.
- Географлар, дөнья читенең ут һәм яктылык бирү буенча Украина белән Кырым чигендә икәнен ачыкладылар.
- Хәрби прокуратура “дедовщина” очрагының фәнни роталарда барлыгын ачыклады: карт солдатлар, отбойдан соң, яшьләрне югары математика мәсьәләләрен чишәргә мәҗбүр иткәннәр.
- Кабан күлендә ике күзле, йөзә торган канатлы һәм бер койрыклы бик матур балык тотканнар. Ул, бу күлнеке түгеллеген әйтеп, бәргәләнеп кычкырган.
- Ана капиталын биш балалы ана офшор аркылы алдырган.
- Инглиз галимнәре, фәннең алар булышлыгыннан башка да яши алачагын ачыклаганнар.
- Барлык экстрасенслар, үлгәннән соң, ТНТ каналында калачаклар – бу исбатланган.
- Шәһәр бәдрәфләрендә “Тормышыңны чиста кәгазьдән башла!” дигән флешмоб уздырылган.
- Шәһәр читендәге трассада өч ел торган путана, география буенча кандидатлык диссертациясе яклаган.
- Яңа микрорайондагы гастарбайтерлар бригадасы яңа йорт төзүне югары этаждан башлаган.
- Кәҗә белән юлбарыс турындагы яңалыклар рейтингы кризис, Сирия, Украина яңалыклары рейтингын узып киткән.
- Сатуга Барби-яга курчагы чыкты.



Валерий ТАРАСЕНКО

ШОМБАЙ болай диде...




Хөрмәтле Чаян! Илнең икътисадына ни булганын һич тә аңлый алмыйм. Аның хәле турында безгә бөтенесен дә әйтеп бетермиләр бугай... Берәрсе аңлатып бирсә иде.

И. РӘШИТОВ

БӨГЕЛМӘ

– **Аңлатам,** – диде Шомбай ага, укучының хатын укып чыккач. – **Хәлләрнең хәле бик шәп, яхшырганнан-яхшыра бара. Ә менә икътисад турында моны әйтеп булмый...**



Валентин ДРУЖИНИН



Хөрмәтле ата-аналар!

Россиядә тыелган ИГИЛ халыкара террористик оешмасының эшчәнлеге активлашу сәбәпле һәм балалар бакчасы территориясенә чит кешеләрне кертмәү максатыннан бакча капкасын эчке яктан келәгә бикләп керүегезне үтенәбез.

Балалар бакчасы администрациясе.

Теләсә нинди максаттан хатын-кыз белән танышырга телим.

Яңа туган мәче баласын яхшы күңелле, назлы, кайгыртучан кешегә бирәм... йә батырып үтерәм.

Чәршәмбе көннәрендә җитди мөнәсәбәтләр өчен чибәр кыз эзлим.

(Белдерүләрдән)

Николай ВОРОНЦОВ



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Халык бәхете өчен көрәшүчеләр бәхетле кешеләрне яратмыйлар.
Хәтта аның рөхсәте белән дә нәчәлниктән акыллырак булырга ярамый.
Талантлар белән көрәшкәндә без – даһи.
Дөнья – театр. Тик беркем дә үз ролен уйнамый.
Мылтык ярдәмендә казарма гына төзеп була.
Чүлдә бөтен кешегә дә җылы урын җитә.
Сәгатькә карап алырга да вакыт җитми.
Бөтен эш тә эшләргә өйрәнмәгәннәр тарафыннан башкарыла.
Иң намуслы каракларны сайлыйк!
Гражданнар сугышы булмаячак: гражданнар бетте.
Берәүләр кешелеккә чыкты, икенчеләр кеше булып калды.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)

Илдус АЗИМОВ



Евгений ОБУХОВ

ТӨНГЕ ТАРИФ

Кичке унбер тулуы була – тынлык турындагы закон гамәлгә керә. Өстәге фатирдагы хуҗабикә кер юу машинасын ялгап җибәрә. Юк, мин аны гаепләмим, зарланмыйм да. Безнең йортта электричествога төнге тариф бик арзан. Кризис заманында аннан файдаланмау гөнаһ булыр иде.

Өстәвенә, ул ялгыз түгел. Уң яктагы күршеләр төн уртасында ашарга утыралар. Тәрәзәләрендә – төсле Яңа ел утлары диярсең! Гриль гүләп тора, микроволновкалары гөжли, электр чәйнеге сызгыра! Савыт-саба шалтырый, кашык-чәнечкеләр чылтырый, өстәл янында күңелле әңгәмә бара.

Дөрес, бу тавышларны сул як күршенең телевизоры бераз томалый. Белмим, ул телевидение программаларын кем төзи торгандыр – шундый шәп фильмнар куялар! Комедияләрендә бөтенесе кырылып бетә, боевикларында барысы да исән кала, ә фантастикада бөтенесе дә нәкъ тормыштагы кебек – күзеңне алырлык түгел.

Мин үзем дә кушылып китәм, әлбәттә... Көндез йоклаучыларны борчымас өчен перфоратор белән төнге уникедән соң гына эшли башлыйм.

Тик бер нәрсә борчый: утка төнге тарифны бетерергә җыеналар дигән хәбәрләр йөри. Әгәр дә бетерсәләр, бик җәл – без бит төнге яктыда яшәргә ияләнеп беткән идек инде!

Кыйммәт БАЛАКАЙЛАР

Бала үстерү беркайчан да җиңел эш булып саналмаган. Билгеле булган агач утырту, йорт салу һәм малай үстерү җыелмасының соңгысы – иң катлаулысы һәм иң кыйммәтлесе. Памперслардан башланган чыгымнардан алып, еллар буена ата-ананың җилкәсендә авыр йөк булып тора. Балалар бакчасы өчен түләү бу чыгымнар рәтендә аерым урын алып тора. Әйтергә кирәк, аның күләме буенча Татарстан беренчеләр санында йөри.

Инде бүгенге көндә квитанцияләрдәге сумма уйланырга мәҗбүр итә – аена 3 мең сум. Чагыштыру өчен мисаллар китерергә була: Самарада ул – 1300 сум, Волгоградта – 1700, ә һич тә ярлы булмаган Санкт-Петербургта барлыгы 1100 сум тәшкил итә. Республикабыз беренчелекне бирергә теләми: яңа елдан түләү тагын 8 процентка артачак.

«Ничек инде? – ди чиновниклар. – Бар нәрсәгә дә бәяләр үсте, персоналның хезмәт хакы да артты...» Ә ата-аналарның үз фикере. Гаиләләрдә керемнәр артмый, балаларны бакчага йөртү хәлдән килми торган купшылыкка әйләнеп бара. Җирле хакимият уйлап чыгарган абонент түләве дә бик шатландырмый – әгәр бала нинди дә булса сәбәп белән бакчага йөрми икән, түләү күләме шул килеш саклана.

Җавапка "төпле" дәлил китерелә: бер бала өчен чынлыкта 8 мең сум китә. Тик ата-аналар моны үзләре дә бик яхшы белә: айлык квитанциядәге сумма бакчага тотылган акчаның өлеше генә. Аларның кесәсен даими рәвештә капшап торалар: группа өчен келәмнәр, уенчыклар, китаплар, савыт-саба, хәтта бәдрәф кәгазе – бөтенесе дә ата-ана акчасына алына.

Өстәвенә, үзен ихтирам иткән һәрбер мәктәпкәчә учреждениедә "өстәмә үсеш" группалары бар: хореография, инглиз теле, аэробика... Баланы анда йөртү ирекле, әлбәттә, тик менә язылмыйча кара – "үсеш акчалары" бакчаның үз фондына бара шул. Бу тагын аена 700 сум чамасы дигән сүз. Әле башка "ирекле" чаралар – театрга билетлар, фотога төшүләр. Һәм иң мөһиме: бәйрәм саен тәрбиячеләргә бүләкләр алу!

Мондый "салымнар" рәсми рәвештә тыелган, әлбәттә, ләкин алар беркая дә китми, бары тик формасын гына үзгәртә. "Савым сыерлары"ның башларында бер уй бөтерелә: ул акча кая китә соң? Бюджетта акча каралган, түләүләр вакытында килеп тора: бөтенесен бергә кушсаң, безнең балалар борыннарын алтын җептән бәйләнгән кулъяулыклар белән сөртергә тиеш бит! Тик кырыс чынбарлыкта хәтта ашау мәсьәләсе белән дә документ һәм отчётлардагы кебек шома түгел. Күптән түгел Түбән Кама балалар бакчаларының берсендә срогы чыккан 52 килограмм тавык ите тапканнар. Сабыйларга шуннан шулпа пешергәннәр, кыздырма әзерләгәннәр. Казанда исә балаларга срогы чыккан солыдан ботка, ачыган каймак ашатканнар.

«Ата-ана түләүләренә компенсацияләр бар лабаса!» – дияр хәбәрдар укучы. Кызганычка каршы, анда да үзгәрешләр кертелде. Узган ел ул процент, ашауны исәпләмичә, баланы йөрткән өчен алынган суммадан чыгып билгеләнә иде. Ә 2016 елдан ул уртача хезмәт хакыннан чыгып исәпләнәчәк. Компенсациянең гомуми суммасы 1522 сум итеп билгеләнгән. Аның 522 сумы – ашау өчен, шуңа күрә гомуми суммадан алына. Менә шундый мәктәпкәчә балалар өчен хәйләкәр арифметика!

Күптән түгел Зәйдә яшәүче бер ана, җирле хакимияттән өметен өзеп, Россия президентына хат язган. Ярдәм итегез, Владимир Владимирович, 10 мең хезмәт хакы белән ике баланы бакчага йөртергә мөмкинлегем юк. Алла хакы өчен, Указыгыз белән түләү күләмен киметегез! Җавап әлегә килеп җитмәгән, тик бу мөрәҗәгать астында инде 30 мең татарстанлы кул куйган.


Ә акчага көйләнгән мәктәпкәчә белем бирү процессы һаман алга бара. Күп ата-аналар балаларын мәктәпкә озату көненең тизрәк килеп җитүе турында хыялланалар. Беркатлылар: бездәге түләүсез белем бирү системасында арзан әйбер түгел бу. Анда, ичмасам, айлык түләү хакы юк. Хәзергә...

Людмила САФИУЛЛИНА

Виталий ПОДВИЦКИЙ







Заһир ХӘКИМОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Александр СЕРГЕЕВ



• • •

Куптән түгел генә миңа: “Егетең сиңа хыянәт итә, бер кыз белән генә дә түгел!” дигән СМС килде. Шуннан бирле мине: “Кайчан соң әле минем андый егетем барлыкка килгән, аның белән күптәнме очрашам һәм хатыныма нәрсә дип әйтим?” кебегрәк сораулар борчый.

• • •

– Әбекәем! Сталин кем ул?

– Сталинмы? Ничек дип сиңа аңлатырга?.. Менә синең Google сыман нәрсә инде ул – син аңа сүз әйтәсең, ә ул сиңа, ничек әле русча?

– Ссылка!

– Әйе.

• • •

– Кума, Порошенконың балалары бармы?

– Бар. Дүртәү.

– Әйтәм җирле, миңа, Янукович вакытындагыга караганда, икеләтә начаррак яшәргә туры килә.

• • •

Кризис чорында исән калу өчен киңәшләр.

Шәхси машинаңнан җәмәгать транспортына күчеп утыру. Кафеда ашап йөрүләрне бетерү, үзең белән өйдән алып килгән банкадагы ризыкка күнегү. Ашамлыкларны акция чараларында сатып алу, кием-салымның бәяләре очсызланган чакларын көтеп йөрү. Кинога аена бер генә мәртәбә бару...

Сорау! Әгәр мин инде кризиска хәтле дә шулай яшәгән булсам нишләргә?

• • •

– Ишеттеңме, нефтьнең бәясе 40 доллардан да түбән төшкән! Безнең хөкүмәт нишләр инде болай булгач?!.

– Мөгаен, бензинга бәяне күтәрер...

• • •

“Платон” системасының авыр йөк машиналарыннан түләү алу буенча уңышлы эшли башлау нәтиҗәсеннән соң, “Сократ” системасына күчү карары кабул ителгән: теләсә нинди саннар датчигы күрсәтүе сайлый һәм бюджетта эшләүчеләр кыскартыла. Ә “Аристотель” эшләнмәсе күрсәтүенчә, датчик түрәләрне “арестовать”, ягъни кулга алуны тәкъдим итәчәк.

• • •

Аракыга, тәмәкегә, бирән сыман тыгынуга акча кызганмыйбыз, ә менә дәвалануга акча тотасыбыз килми.



Хәмис ГАРИПОВ

МАЙМЫЛ ЕЛЫ БЕЛӘН!

Маймыл елы килә... Маймыл елы,
Маймылланып беттек болай да...
Маймыллану бара бөтен җирдә,
Ышаныч тик бары Ходайда!

Маймыл елы килә... Маймыл елы,
Белмим ничек кая качарга...
Хезмәт хакы бигрәк "маймыллашты" –
Бананга да җитми, ашарга.

Маймылдан чыкканбыз диеп безне
Исбат иткән Дарвин бабабыз.
Киресенчә, Ходам, без бит хәзер
Тач маймылга охшап барабыз?

Маймыл елы килә... Маймыл елы,
Хәерлегә булсын барсы да!
Кеше булып калыйк һәр гамәлдә,
Маймыл елы килеп торса да!


МАЙМЫЛ ҺӘМ КЕШЕ БӘЙЛӘНЕШЕ ТУРЫНДА КАЙБЕР ФИКЕРЛӘР

Кулына таяк тотканнан соң түгел, ә аны тәгәрмәчкә тыгарга өйрәнгәч, маймыл кеше була. **(Борис Крутиер)**
Кеше була торып, дөреслеккә туры карарга курыкканчы, маймыл баласы булу әйбәтрәк. **(Томас Гекели)**
Кешеләр маймылны аңламый. Бу – буыннар бәрелеше. **(Нинус Нестерович)**
Дөрестән дә, кеше маймылга охшаш: биеккәрәк менгән саен, ялангач арты яхшырак күренә. **(Фрэнсис Бэкон)**
Кеше яшәми торган утрауга эләккәннәрнең кайберләре Робинзон түгел, маймылга әйләнәчәк. **(Виктор Шкловский)**
Кеше сыман маймыллардан маймыл сыман кешеләр килеп чыккан. **(Николай Векшин)**
Кеше – акыллы маймыл. **(Артур Шопенгауэр)**
Маймыл – безнең ярлы туганыбыз. **(Жюль Ренер)**
Маймыл белән кешене аерганнан соң, зоопарк һәм цирк барлыкка килгән. **(Перица Йокич)**
Маймыл үзен кеше итеп сизгәннән соң, эволюция башланган. **(Виктор Шендерович)**

Нияз БИШБАЛТА тупланмасыннан



Сергей АНДРИАНОВ



Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ЭНӘЛЕ

МАЙМЫЛ ЕЛЫНА ӨМЕТЛӘР

Маймыл елы... Татар кызы
Урыска барса барсын,
Тик тәрбияләп үстерсен
Татар итеп баласын!


Маймыл елы... Әй, егетләр,
Алсагыз урыс кызын,
Күрсәтегез марҗагызга
Татарның дәртен, тузын!

Маймыл елы белеп килә,
Ниләр көтелә алда...
Алдагысын Алла белә,
Һәм Сәгъдулла Шәйхулла.

Алдагы күрәчәкләрне
Аллага тапшырабыз.
Ач булсак та, тук булсак та,
Путинга ышанабыз.


Виктор БОГОРАД








Александр АЛЁШИН



– Баш иегез! Берни дә эшләп булмый – маймыл елы!

ҖАНЛЫ ПОЧМАК







Антон МАКУНИ

ЧЫН БАТЫРЛЫК...

Кибеткә пистолет тоткан бандит атылып керә.

– Акчаңны чыгар! – дип кычкырды ул, көпшәсен яшь сатучы кызга төбәп.

– Әле генә тапшырдым, – диде тегесе, тәмәке кабызып. – Ышанмасагыз, тикшереп карагыз...

Бандит кассаны ачып карады – анда чынлап та акча юк иде.

– Алайса товар белән алам! Давай, илле шешә аракы бир!

– Алдан әйтеп куям, аракы заводныкы түгел, – диде сатучы, икенче сигаретын кабызып.

– Алайса, нәрсә анда – ысланган колбаса, балык, икра! – дип кычкырды бандит, күзе белән киштәләрне капшап.

– Бөтен продуктлар да контрафакт йә срогы чыккан. Ашказаныгыз авыртачак. Гастрит килеп чыгуы да ихтимал...

Сигаретын тартып бетереп, сатучы чираттагысына үрелде.

– Күп тартасың! – диде бандит.

Һәм игътибар белән кызга карап алды. Алкалар, балдаклар, күкрәгендә ялтыравык ташлы брошка.

– Әһә! Бриллиантлар! – дип шатланды ул. – Сал бөтенесен дә!

– Берсе дә чын түгел алар! Бижутерия! – дип, чыраен сытты кыз.

Бандит пистолетын төшерде, кесәсеннән сигарет чыгарды һәм тартып җибәрде. Тәмәке сөременнән кибеттә электр лампалары тоныкланды.

– Менә нәрсә, – диде әзмәвер, авызыннан төтен боҗралары чыгарып. – Зинһар өчен, әйт әле – бу кибеттә хет бер генә булса да чын әйбер бармы?

– Бар! Янгын сигнализациясе! – дип чәрелдәде кыз һәм прилавок астына ташланды.

Шул чакта кибеткә өерелеп елгыр янгын сүндерүчеләр килеп керде. Көчле су агынтысы бандитны аягыннан бәреп екты. Берничә минуттан барысы да тәмамланды: юеш тавык төсле талаучы бәйләнгән хәлдә янгын сүндерүчеләр күзәтүе астында идәндә ята, ә яшь сатучы кыз тиз генә килеп җиткән оперативникларга хәлнең ничек булуын сөйли иде...

Икенче көнне аны Эчке эшләр идарәсенә чакырдылар һәм бүләкләр тапшырдылар. Чып-чын бүләкләр. Чын батырлык һәм гүзәллек өчен.





Виталий ФЕОКТИСТОВ



Эрнест ДЫШАЕВ



Виталий ФЕОКТИСТОВ



ЮГАРЫ ГРАДУСЛЫ БУЫН

“Пепси” буыны җәмгыятьтә үз урынын тапты. Аңа алмашка күпкә “җитдирәк” омтылышлы балалар килде. Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәридә Яркәева әйтүенчә, республикада хәзер чын мәгънәсендә яшүсмерләр алкоголизмы эпидемиясе котырына. Бары тик бер ел эчендә тормышка аяк басучылар арасында “яшел елан” кочагына кергәннәрнең саны 43 процентка арткан! Хәзер наркологлар күзәтүе астында 200 яшүсмер тора. Һәм бу сан ел саен арта тора. Әгәр бу авыруга каршы дару юк икән, кулга каеш алырга вакыт!

БҮЛӘК ИТЕП ЧӘЧӘКЛӘР ӨЗМӘДЕМ...

Гади кешегә хас бөтен нәрсә чиновник өчен хәзер чит әйбергә әверелде. Дөрес, ирекле көннән түгел. Күптән түгел Россиянең Хезмәт министрлыгы чиновникларга бүләк кабул итүне генә түгел, ә бүләк ясауны да тыйды. Бу исемлеккә чәчәкләр, конфетлар, хәтта календарьлар да керде. Оешмаларның үз хезмәткәрләре өчен Яңа ел бүләкләренә акча тотуы да законсыз гамәл булып санала. Бердәнбер рөхсәт ителгән бүләк – үз кулларың белән ясалган берәр нәрсә. Тик моның өчен кулларның тиешле урыннан үсүе дә кирәк бит әле...

ПУТИННЫ АДЫМЫННАН ТАНЫЙМ...

Путинның гадәттән тыш сәләтләре бөтен дөньяга тынгы бирми. Хәтта безнең президентыбызның... йөрешен өйрәнүче тикшеренүләр барлыкка килгән. Нидерланд галимнәре Путинның йөрү рәвешен башта аның дзюдо белән шөгыльләнү нәтиҗәсе дигән фикергә килгән булганнар. Ләкин совет заманындагы КГБ хезмәткәрләре өчен әсбап белән танышканнан соң, ахыргы нәтиҗә ясалган – Путинда “укчы йөреше”. Мондый очракта уң кул бөтенләй диярлек йөрми – теләсә кайсы вакытта корал тартып чыгару өчен кирәк бу. Әлеге фәнни ачыш Америкада да зур кызыксыну уяткан. Җирле юморист Стивен Колберт АКШ президентына шуңа охшаш берәр нәрсәгә өйрәнергә тәкъдим иткән: “аның (Обаманың) һәрчак болганып йөри торган кул-аяклары белән кораллану өлкәсендә артта калачакбыз”.

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Мәскәүдә “Крокодил” дигән гигант ябылды, ә “Чаян” исән. Моның сере нәрсәдә?

Алмаз Хәмзин: Телевидениенең барлык каналларында “Крокодил” сурәтләгәнгә караганда да “мәзәклерәк” тормыш бара... Шуңа күрә “Крокодил” үлде. Ә Татарстан каналларында бар да әйбәт – һаман җырлыйбыз, биибез, “Чаян” гына чага тора.

Р. Н.: Соравыма берәү: “Тәмәке эчмим, аракы тартмыйм...” дип җавап бирде. Бу “Чаян”чамы?

А. Х.: “Әбиләр белән йөрим” дигәнен дә өстәсәң, “Чаян”ча була.

Р. Н.: Язмыш (ә бәлки Ходай) бәхетне нигә безгә кашыклап, ә кайгыны капчыклап өләшә?

А. Х.: Бәхет – күп булырга тиеш нәрсә, ләкин ул сирәк, ә кайгы аз булырга тиеш, әмма ул бик күп. Чүп үләне кебек. Кирәк булмаган нәрсәне мул итеп өләшәләр.

Р. Н.: Шушы арада акыл тешен алдырдым әле. Акыл калды шикелле, ә теш юк!

А. Х.: Акыл тешкә бәйләнгән булса, минең кирәге булмас иде, Рашат дус.

Р. Н.: Чит илдә хәтта этләр зиратында да тәртип икән. Әллә, мәйтәм, шунда китикме?

А. Х.: Бу фикереңне укыгач, синең акылыңның беркадәре, чыннан да, тештә икән дип уйлап куйдым әле мин.





“ЧАЯН” ЮЛДАШЫ



Алманың агачыннан ерак төшмәве хак булгандай, Хәнәфи Бәдигыйны укучылар да чаянчылар да яхшы беләдер дип әйтү дә хакыйкать янәшәсендә үк тора. Моның шулай икәнлеген соңгы егерме елда аның “Чаян” журналында дөнья күргән, 1700 юлны хасил иткән 100 дән артык әсәре раслап тора. Бу – уртача һәр ике санның берсендә аның берәр әсәре басылып чыккан дигән сүз. Ул моны түкми-чәчми теркәп-язып барган. Күпчелеге шигырь булса да, алар кыйсса, пародия, эпиграммалар рәвешендә дә, фельетон, палиндром, тавтограмма, төрткеле җөмләләр сыйфатында да язылуы белән игътибарны җәлеп итә.

Җәлилче-галим, мөгаллим, шагыйрь, байтак санда китаплар, фәнни хезмәтләр авторы, урта мәктәп директоры, югары уку йортларында доцент, профессор дәрәҗәсендә декан ярдәмчесе, проректор вазифаларын башкарган Х. Бәдигыйның “Чаян”ны да шулкадәрле үз итүенең берәр хикмәте бардыр бит дип уйлап куярсың. Һәм, чыннан да, Казан дәүләт университетында укыганда ук юмор-сатирага кагылышлы курс һәм диплом эше язып остарган икән. Соңга таба М. Җәлилнең зәвыклы юморын да, Г. Тукайның үткен сатирасын да фәнни нигездә шактый җентекләп өйрәнгән.

75 яшьлек күркәм юбилее белән тәбрикләп, чаянчылар һәм күпсанлы укучылар исеменнән аңа яңа иҗат уңышлары юлдаш булсын дип телик.

ЧАМА БЕЛҮ КИРӘК

Шөпшә белән төклетура
Чама белеп бал җыя.
Түрәләр һәм яңа байлар
Көне-төне мал җыя.

Байлар – сорыкорт, каһәрле
Хәрам чутка яшиләр.
Бал кортлары – гади халык,
Хәләл эшле кешеләр.

УРТАЧА ЯШӘҮ

“Тормыш яхшыра бара!” – дип,
Күтәрергә ил данын,
Фәкать арттырырга кирәк
Миллиардерларның санын.

Шул исәпкә тиз артачак
Уртача хезмәт хакы.
“Ур-ра!” – кычкырып кул чабар
Рәсәйнең хезмәт халкы!

ЯҢА САЛЫМ

Сарыкларның ит, йон салымнары
Аз тоелды бер көн аюга:
– Тире налогы да салсак, безгә –
Шәп чыганак булыр баюга.

Әлегәчә җайлап, уптым түгел,
Чама белеп кенә алына.
Үзләренә – тояк, койрык, колак –
Җитмәгәнме сарык малына?

Без бит бүре кебек ерткычланып,
Бугазыннан канын эчмибез.
Бөтен урман халкы күреп тора:
Законлы юл белән эшлибез.

– Бар, саескан, зур җыелыш була,
Киек-җанварларга хәбәр ит:
Салымнарны раслау була бүген,
Кирәк түгел безгә хәрам ит!

СИНГАПУР СЫРАСЫ

“С” хәрефенә тавтограмма

Салкынча Сингапур сырасы сихәтлеләрдән санала. Сыраны сөйкемле сөякле сылулар сата. Сингапур сылулары сингапурча сөйләшкәнне сөяләр. Сөйләшмәсәң, сантыйга санап, санга сукмыйлар. Сыраны сузынкы, сырлы-сырлы сызыклы сапфир сыман саплы савытларда саталар.

Сингапурда сыраны сәгатьләп санап, сайланып сатмыйлар. Сорасаң, салып бирәләр, сорамасаң, салмыйлар. Сыраханәләрдә саранnарга, сөрхәнтәйләргә сөйләшмичә саталар.

Сәяхәтчеләргә сораштырмыйча, сатулашмыйча, сизгерлек саклап саталар.

Саф су салганга, Сингапур сырасы симертми, сусатмый.

Сөйкемле, сылу Сингапур сыра сатучылары сәяхәтчеләрдән сорый:

– Сезнең Сарманда Сингапур сырасы саталармы соң?

ПАЛИНДРОМНАР

КАССА БАССАК?

– Касса бассак,
Йабагай,
Алай йала йага бай!
– Касса? Банык кына бассак?
– Аскат наган такса?
Астан атса?
– Атса – баста!

• • •

- Үгетләп тәп-ләп тегү.
- Сиз, иркәм, мә кризис!
- Ага, йаз! – Эше зайага!
- Ә тик айак эзе кайа китә?
- Уакас, ат кай йакта, сакау?
- Нәки йыш ашый икән, аз йаза.

ТӨРТКЕЛЕ ҖӨМЛӘЛӘР

- Кеше теләгәнчә бәхетле дә, уйлаганча бәхетсез дә түгел.
- Казна караклары булмаса, вакларны үрчи алмас иде.
- Карак кулындагы акча тотылудан, халык кулындагы отылудан курка.
- Ялган никадәр татлырак булса, авызда калган тәме шулкадәр ачырак була.
- Оста алдакчы ялганын чынның эченә чеметемләп кенә куша.

КАРБЫЗЛЫ “ЧАЯН”

– Лутчы карбыз ашыйм мин! – дип,
Кысып калмыйча янга:
– Ашау качмас! – дип язылдым,
Карбыз алмый, “Чаян”га.

ТЕРӘК

Көнгә кирәк кояш нуры,
Күңелгә «Чаян» кирәк.
Юмор – хезмәт кешесенә,
Ил башына да терәк.



Дмитрий ФИЛИППОВ

СИХРИ КӨЧ

Соңгы вакытта мин шигъриятне ярата башладым. Менә, мәсәлән, Һади Гафуриның юллары: «Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл...» Нинди көчле сүзләр! Төнге икедә укый башлавым була, стенага күрше шакый башлый, алкышлый, күрәсең.

Йә менә Габдулла Такташ. «Су буеннан әнкәй кайтып килә...» дип әйтүем генә була, ишегалдында эскәмиядә утыручы әбиләр үксеп елый башлый, күзләрен сөртеп, кулъяулыкларын сыга... Сәнгатьнең сихри көче шулдыр инде!

Мин үзем урам себерүче булып эшләсәм дә, гүзәллеккә һич битараф түгел. Бер өем карны көрәп атасың да, шунда ук шигырь укыйсың... Боз ватасың да, тагын шигъри юллар искә төшә... Юлга ком сибәсең дә Габделҗаббар Афзал китабын ачып җибәрәсең...

Ул китаплар чүп контейнерлары янында бик күп аунап ята. Халык Интернет барлыкка килү белән, китаплардан котылу җаен эзли башлады. Ә заманында аларны блат белән генә алып була иде... Әнә баскыч астында минем көрәк-себеркеләр янында чын китапханә җыелды. Буш вакытларда нәрсә язганнарын укыштыргалыйм... Аларның миңа килеп эләгәсен белеп торганнар, диярсең...



Александр КОСМЫЛИН



Игорь КИЙКО





Илдус АЗИМОВ



Алексей БУЛАТОВ











КЫШКЫ ТРАССА ТАБЫШМАГЫ

Чаян дус! Кышкы трассаның ребус һәм шарада чишә торган урын булмавына минем белән син дә килешәсеңдер. Аның өчен авто йөртүчеләрнең вакыты һәм теләге дә юктыр, дип уйлыйм. Тик шулай да кайвакыт безгә юл китереп чыгарган табышмакларны чишәргә туры килә. Моңа күп яуган кар өеме түгел, ә аны җыя торган техника сәбәпче була. Әлеге техника "фонтаныннан" юл билгесе нинди рәвештә калганын күз алдына китерү кыен түгел...

Без, юлчыларга, әлеге табышмакны юрарга гына кала: текә борылышмы, бозлавыклы юлмы әллә гаишник радарымы... Тик бер нәрсә ачык: юрый алмаган табышмакның нинди юл һәлакәтенә китерәчәге... Ярый ла, бампер, ишек кенә бәрелеп калса... Ә фаҗигагә китерсә?

А. ХӘКИМОВ

КАЗАН

МАТУРЛЫК КОРБАНЫНА ӘЙЛӘНМИК!

Кадерле Чаян! Хатын-кызның матур булып күренәсе килү – табигый хәл. Әлеге халәттән кайбер үткенрәкләре үз кесәсен калынайтып калу ягын карыйлар. Мисал өчен, яңа ачылган гүзәлләр салоныннан, йөз-битемнең торышын сафландырып һәм яшәртеп җибәрү нияте белән бер генә шалтыратмадылар миңа. Янәсе күпкырлы күзәтүләр китергән кулланучылар ихтыяҗыннан чыгып, бөтенләй бушка үткәрелә икән әлеге процедура.

– Ничек инде, яшегез утыздан узып та, бер генә дә махсус белгечтә булганыгыз булмадымы? – дип кызыксынды телефоннан ханым. – Безнең косметолог килеп, иң яңа косметика могҗизасын күрсәтеп китәргә әзер!

Бик каты кыстый торгач бирештем тагын үзем. Очрашу вакытын сөйләштек. Шулай итеп, минем ишек катында зур косметология белгече дә пәйда булды. Чемоданын ачып, миңа бөтенләй таныш булмаган "яңа линиясен" мактый да башлады. Бик озак мактый торгач, әлеге ханымның нәрсә өчен килгәне аңлашылды. Уң як биткә крем сөрткәч, соклануына тыела алмыйча кычкырып ук җибәрде:

– Йә Алла, ничек яшәреп киттегез! Битегез тәмам персикка әйләнде, билләһи, сезгә әлеге кремны алып җибәрергә кирәк!

Мин ике битемнең аермасын табарга тырышып, әлеге ханымга төбәлдем:

– Ә икенче ягы ничек?

– Анысы бушка күрсәтелгән рекламага керми, менә бу кремны мең сумга алып җибәрәсез дә, үзегез сөртеп куясыз! – дип дәвам итте ханым.

Әлбәттә, ярты ягы яшәрмәгән бит белән йөрисем килмәсә дә, кибеттә ун тапкыр арзанрак кремны да аласым килмәде. Косметологны озатырга туры килде. Киткәнче иннек алырга үгетләп маташты.

Әлеге салоннан башка шалтыратулар булмады. Күрәсең, бернинди яшәртү ысуллары да булышмый торганнар исемлегенә эләктем...

Л. ГЫЙМРАНОВА.

КАЗАН.

Алмаз ХӘМЗИН

“КЫСКАРТУ”


Татар җәмәгатьчелеге сөекле шагыйребез Хәсән Туфанның 70 еллыгын тантаналы төстә үткәргән көннәр. Гадәттәгечә зал шыгрым тулы. Күрше республикадан, Мәскәүдән бик күп кунаклар, делегатлар килгән. Залда бөркү, тамашачылар кулларындагы чакыру билетларын җилпеп утыралар. Менә инде Башкортстаннан килгән олы кунак – әдип Сәйфи Кудаш (Сәйфи аганың күзләре күрми икән) сәгатькә якын Туфан турында якты истәлекләр сөйли. Сәйфи аганың озакка сузылган чыгышы залдагыларны бик талчыктырды, ахрысы, президиумдагылар үзара сөйләшә, кашына башлады. Кемдер борын җонын өзә, кемдер газета укый, кемдер түзә алмыйча сәхнәдән бөтенләй чыгып китә, кайберәүләр ашап та керергә өлгерәләр, ахрысы, чөнки теш арасына кысылган ризыкны чыгарырга бер-берсеннән шырпы сорарга тотындылар. Әнә берсенең аягы, ә берәүнең уңайсыз җире кычыта. Без тамашачыга барысы да күренеп тора. Залда тынчу булса да, безгә кызык спектакль бара. Ниһаять, тантананы алып баручы, мөнбәрдә сөйләүче Сәйфи аганың чыгышын кыскартып булмас микән дип, башкалар белән фикерләшеп алды. Ләкин ничек кыскартырга?.. Татарстан кешесе янына барып: “Сәйфи ага, кыскарта төшегез әле чыгышыгызны”, – дисә, бу әдәпсезлек булыр иде. Килешеп бетмәс безгә башкорт дусларга мондый киңәш бирү. Әһә, уйлап таптылар бугай ситуациядән чыгу әмәлен. Нотыкчыны кисәтүне шунда ук Президиумда утыручы Нажар Нәҗмигә йөкләделәр. Үз кеше бит – Башкортстаннан. Нажар абзыкай да аптырашта калды шикелле. Сәйфи агай сөйләп торган трибунага бер генә кеше аркылы утырса да, сигез кешене ерып сулга узды һәм Президиум артында уйланып йөргәннән соң, кыяр-кыймас кына янына барып, агайның колагына нидер пышылдады. “Сәйфи ага, кыскарак тот!” – диде, ахрысы. Сәйфи ага, аңладым дигән кыяфәттә бераз тынып торды да, сүзен дәвам итте: “Шулай итеп, 1917 ел килеп җитте...” – диде.

КҮРЕШҮ

Бер елны Казанның бик макталып сөйләнелгән “Каенлык” Сабан туена киттем. Автобуслар ташып кына тора халыкны. Килеп төшүем булды, каяндыр машина кортежы пәйда булды. Шәймиев килгән икән. Машиналарыннан төшеп, бер өер важный кешеләр Президент артыннан мәйданга үтә башлады. Араларында минем белән бергә җырлап йөргән министрлар да бар. Элек бергә кызлар озаткан главалар да, бергә укыган депутатлар да, бергә эчкән начальниклар да. Без кызыксынып кырыйдан карап торабыз. Сизәм, үтүчеләрнең кайберләре мине күрәләр, ләкин күзләр очрашу белән күрмәмешкә салышып, Президент артыннан баруларын дәвам итәләр. Шту син, минем кебек диссидент белән рәҗе ярый күрешергә... Президент ни әйтер?..

Менә Шәймиев бераз гына алга китеп, борылып, халык белән сөйләшә башлады. Ул ярата бит инде шулай иркенләп аралашырга. Минтимер Шәрипович барчабызны да бәйрәм белән котлап алгач, халык арасына качып торган мине күрде дә: “Менә монда Алмаз Хәмзин бар икән”, – диде. Килеп күрешеп, бәйрәм белән котлады. Ул күрешкәч, башка министрлар, главалар, депутатлар, начальниклар да килеп кулымны кысып киттеләр. Хәтта өч ел элек Сабантуйда бурычка акча алган бер сәрхуш та, әҗәтен түләп, иңемнән сыйпап китте.

Борис СТАРЧИКОВ, «Чаян» № 15, 1962




Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 11, 1974



– Комиссар, әле генә ачлыктан интегүче балаларга ярдәм итү фондын талаганнар!

– Вак урлашулар белән өске каттагы бүлек шөгыльләнә!



ХӘТӘР – БАШЫҢА ЖИТӘР

• • •

Хатын сәяхәттән кайтып керә, һәм өендә күпсанлы буш шешәләргә тап була.

– Каян чыкканнар болар? – дип сорый ул иреннән.

– Үзем аптырыйм. Минем беркайчан да буш шешәләр алганым юк югыйсә.



Валерий ТАРАСЕНКО

Виталий ФЕОКТИСТОВ



Виртуаль мәйханәчеләр

Ни дисәң дә, безнең тормыш тоташ уңайлыклардан гына тора. Хәзер бит җаның теләгән әйберне өйдән дә чыкмыйча сатып алырга була. Һәм болар Интернет аркасында! Кирәкле виртуаль кибетнең сайтын ачуың була – бөтен кирәк нәрсәң алдыңа ишелеп төшә. Ишелү генәме соң – елга кебек ургып керә: көмешкәдән алып вискига кадәр, әче балдан Ямайка коньягына кадәр...

Ләкин мондый "уңайлык"ларның нәрсәгә китерергә мөмкин булганын Чаллы шәһәреннән Алексей С.ның аяныч мисалында күрергә мөмкин. Туган көнендә шәпләп күңел ачарга ниятләп, ул Интернет аша "Блэк Джек" вискиена заказ бирә.

Алексей үзенең туган көнен фани дөнья белән хушлашу көне булыр дип уйлаган микән? Юктыр, мөгаен. Ул моны соңгысы булып калмаган бер рюмка виски эчкәннән соң, реанимациягә эләккәч кенә аңлаган.

Монда берничә сан китерү дә урынлы булыр: узган ел эчендә Татарстанда ялган алкоголь белән 217 кеше агуланган. Шул ук вакытта мондый эчемлекләр атна саен 5-6 кешенең гомерен кисә.

Шундый югалтулардан соң, республикада Интернет спекулянтларына каршы сугыш ачтылар һәм йөз илле чамасы "кибет"не яптылар. Алкогольне дистанцион ысул белән сату 2007 елда ук тыелган булуга карамастан, аңа әле дә тәүлекнең теләсә кайсы вакытында заказ бирергә мөмкин. Әйтергә кирәк, моның өчен штраф каралган – шәхси "эшмәкәрләр" өчен 4 мең сум, оешмалар өчен – 40 мең. Товар да конфискацияләнә. Ләкин виртуаль мәйханәчеләрне бу чаралар туктатмый. "Сәүдә"дән килгән табыш җитәрлек, күрәсең...

Шуңа күрә "тамак чылатучыларга", алкоголь сайтларының хезмәте белән файдаланганчы, башта бик яхшылап уйлап карарга кирәк. Эчемлекне хөкүмәт бәясеннән супермаркетлардан алу – арзанлыгына кызыгып, шикле сыекчалардан аяк сузуга караганда хәерлерәктер бит?

Айдар СУБАЕВ

ЧуАр пресса

ТӨБЕННӘН ЧАПКАННАР


Ростов университетының ботаник бакчасында Яңа ел бәйрәмнәрендә гадәти булмаган чыршы "уенчыгы" пәйда булган. Территориядәге бөтен чыршыларны чәнечкеле тимерчыбык белән чорнап куйганнар. Мондый "гирляндаларның" барлыкка килүе – агачларны вандаллардан саклап калырга тырышу. Чөнки узган ел берничә яшел гүзәлне төбеннән чабып алып киткәннәр.


ЦЕРЕТЕЛИНЫ КӨНЛӘШТЕРЕРЛЕК

Якутиянең Уолба авылында гадәти булмаган скульптор яши. Михаил Бонносов тирестән ясалган скульптуралары белән дан казанган. Авылда мондый материал өелеп ята. Бу юлы Михаил авылдашларын әлеге елның символы – тирес маймыллар белән шатландырган.

ЕЛ КАРАГЫ

Ел саен, дөньяда күрелмәгән ахмаклык эшләгән өчен, Дарвин премиясе бирелә. Бу юлы аны Сиэтлда яшәүчегә бирәчәкләр. Бәхетсез америкалы автомобильдән бензин урларга теләп, шлангны бензобакка түгел, ә шакшы су багына тыккан. Мескен, һаваны суырып алганда, бик күп итеп шакшыларны йоткан. Аны шушы хәлдә полицейскийлар тоткарлаган.


Валерий ТАРАСЕНКО



Валентин ДУБИНИН

Эльвира ДЫШАЕВА





Нил БЬЮКЕНЕН (Австралия)



Дарел КЕЙГЛ (Бөекбритания)



Кәрим ЭРШИН (Иран)





• • •

Бабай кеше эскәмиядә елап утыра. Бер егет аннан сорый:

– Бабакай, нигә елыйсың?

– Беләсеңме, улым, минем хатыным яшь, матур...

– Соң, шулай булгач, нигә еларга?

– Ул миңа һәр иртәдә караватыма кофе китерә, төшке ашка тәмле-тәмле ризыклар пешерә, кичкесен – телең йотарлык. Ә төне буе татлы мәхәббәт хисләрендә коенабыз!

– Бабай, син җәннәттә яшисең икән бит! Нигә шуңа шыңшырга?

– Әй, улым, бәла төште шул башыма, бәла... кайда яшәгәнемне оныттым... адресымны...

• • •

Ике ир балыкка баралар. Башта шәп кенә эчеп алалар. Иртән сөйләшәләр:

– Син нигә ятьмәне кырга салдың?

– Син кайда иштең – шунда куелды!

• • •

Блондинка – блондинкага:

– Кичә “Робинзон Крузо”ны укып бетердем. Җүләр дә инде ул. Ничә еллар утрауда яшәп мобильнигыннан шалтыратырга башы җитмәгән.

– Син нәрсә? Беләсеңме, утраудан шалтырату тарифы кыйммәт икәнен!

• • •

– Чибәркәй, мөмкинме сезне берәр чынаяк кофе эчәргә чакырырга?

– Нәрсә, коньякка акчаң җитмиме әллә?

• • •

Илебез җитәкчеләренә рәхмәтебезне белдерәсебез килә. Ярлыларга һәм мохтаҗларга түбән дәрәҗәдәге пособиеләр бирү нәтиҗәсендә, шулай ук хезмәт хакларыбызның шактый аз булуын искә алып һәм икътисадыбызның мөшкеллегенә таянып, алар безне кесәлар ташкыныннан һәм теләсә нинди алдакчылардан, юньсезләрдән саклап калдылар.

• • •

Аптекада.

– Бүген әбиләр йөрәк даруларын бигрәк күп алалар, магнит давыллары булганга микән?

– Юк, аның өчен түгел. Фатирга түләү кәгазьләрен алганнардыр!..



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН) № 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**

Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЁШИН**

Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**

Марс САБИРОВ

Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**

Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**

Артём СУББОТКИН

Алмаз ХӘМЗИН

Лилия ӘХМӘТОВА

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты: Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.

Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**

Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.

«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.



Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, тел./факс: 222-05-54.

16+

E-mail: chayan@bk.ru

Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

ХӘЗЕР ДӘ ШУЛАЙ

Нинди дә булса мөлкәтеңне хосусыйлаштырырга керешсәң, әллә нинди бюрократик каршылыкларга очрап, кирәкмәгән аңлатмалар тутырып, судлар аша үтеп, кырыкмаса-кырык оешмалар ишеген шакып, байтак акча түздырып, елап-ялварып, йөрәгеңне эштән чыгарып бетерәсең. Бу уңайдан, әлеге мәсьәләгә ачыклык кертү өчен, элеккеге вакыттагы бер хәлне искә төшереп үтү урынлы булыр.

Алмаз ХӘМЗИН

ЗАКОНЛЫ КОММЕНТАРИЙ

Тегени муниципаль районының “фәлән авыл җирлеге” муниципаль оешмасы җирләре чикләренең картографик билгеләмәсенә (“Тегени муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Законның 1 нче кушымтасына). Шул авыл кешесе Белдекле Җаббар комментарие.


Җәүдәт ЮНЫС

Фәлән авылына тиешле җир кишәрлекләренең чиге, Төгән авылы ягындагы Шүрәле чокыры буендагы кәкре наратларның, Атсыз Әгъзам кизләве ягыннан санаганда, җиденчесе төбендә башлана да, Фәләннән Фәсмәтәнгә бара торган юл буена утыртылган агачлар рәте беткән урындагы, инде 1978 елны ук күмелеп, хәзер кычыткан белән капланып беткән үлән базыннан төньякка табан 2,33 чакрым чамасы бара, шуннан соң чик, басу буйлап якынча 631 адым, югалган савым аппараты бидоны аркасында Тукран Мортазасының хатыны сыер савучы Озын Зөләйха белән талашкан һәм аны “сасыган балык” дип үртәгән, шуның аркасында кибеттә боламыклы винога чиратта торган җиреннән Тукран Мортазасы тарафыннан алып очыртылган һәм дояркалар кулы белән рәхимсез рәнҗетелгән чатан көтүче Имаметдин бер ботагын яндырган ялгыз имәнгә кадәр сузыла, аннары төп-төгәл 237 адым гел җил кузгала торган якка бара, шуннан чама белән ике йөзләп адым мал брачы Хамәтҗанның шома пеләше кебек тигез кыр буйлап уза, инде килеп, шайтан таягы урман кебек үрчегән төбәк буйлап 778 ләп адым узгач, мидәлсез Фронтовик Шириязданнан әллә кайчан, төгәлрәге 1964 елны ук, баткаклыкка батырып калдырган, әле хәзергәчә тартып чыгарылмаган һәм, әлбәттә, соңгы башмагына кадәр таланып беткән ДТ-54 тракторы тырпаеп торган урынга кадәр дәвам итә, шуннан соң безнең җир чиге Шайтан (тәүбә әстәгъфирулла) канавының төбе буйлап 2194 адым тирәсе, ягъни ак таш чыгарыла торган Бәдри чокырына кадәр бара (хәзергәчә исән-сау гражданнар сугышы ветераны Габидулла бабай сөйләгәнгә ышансаң, Әхмәдиҗан кулак нәкъ шуннан алган таш белән үзенә ике катлы бәдрәф ясаган булган, аннары хәчтерүш, авылдашларын җәлләп, аны 1932 елны II Интернационал исемендәге колхозга бүләк иткән, колхоз идарәсе учут кенәгәсенә ул бәдрәфне “тегермән” итеп теркәгән), алга табан чик якынча 960 адым Алпавыт урманына таба китә, ягъни теге елларда “Ленин байрагы” колхозының умартачысы булып эшләгән саран Микулайның баштан арендага гына алып торган, ә хәзер инде кортлары һәм оялары белән, кышлардык куышлары һәм өе белән, бер машинасы, ике тракторы, печән чабучы тагылма агрегаты һәм ике ашлык җыю комбайны белән ничектер хосусыйлаштырган умарталыгы юнәлешендә уза, аннары ата ялкау янгынчы Закирҗан Халтуридзеның бер тапкыр да туйганчы ашатмаган, шуның аркасында шыр скелетка калдырылган, ахыр чиктә үзенең иблис газраиле Халтуридзедан качып китергә мәҗбүр булган карт алашасы 1983 елда батып үлгән урынга кадәр сузыла, шуннан Фәсмәтән юнәлешендә китеп, Төгән кибетчесе Гыр-гыр Григорий бакчасының иң көньяк коймасына 342 адымнар барып җитмәстән, үз теләге белән пенсиягә чыккан дүрт тапкыр коммунистик хезмәт ударнигы һәм җиде тапкыр социалистик ярыш җиңүчесе Шәмсиганиев Блюхер Моторович үзенең бәрәңге бакчасының почмагы дип санаган электр баганасына җитә, аннан чик, туры сызык булып, мәктәп директоры Миндияр Архимандритович аңлатканча, безнең якларда илнең Көнчыгыш чиген япун, кытай, монгол һәм башка Себер халыкларыннан саклар өчен казып өелгән тарихи вал буйлап башланган ноктасына кадәр бара.

(Документ ике тапкыр кыскартып бирелде.)

Уйна да, уйла да!

ЧАЯНВОРД



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. “Ашыгыч ярдәм” табибының беренче кагыйдәсе?

2. Ни өчен телепроект “Дом-2” дип атала?

3. Украина Рәсәйгә бурычын түләсен өчен нишләргә кирәк?

4. Өч хәрефтән торган русча әдәпсез сүз?

5. Культура һәм ял паркында гипстан ясалган ишкәк белән торучы кызның яраткан җыры (русча)?

6. Ни өчен бездә узган елның декабрь аенда көннәр җылы торды?

7. Американлыларның беркайчан да Айда булмаганлыкларына нинди төгәл исбатлау бар?

ҖАВАПЛАР

1. Никадәр соңга калып киләсең, шулхәтле төгәл диагноз. 2. Чөнки анда фәхешханә һәм җүләрханә йорты берләштерелгән. 3. Русчалап әйткәндә, нинди дә булса отмороженный коллекторларга бирергә кирәк. 4. Мат. 5. „Вот стою, держу весло...“ 6. Рәсәйлеләргә мисыр һәм төрек курортларын югалтуны компенсацияләү хисабына. 7. Анда әлегә хәтле бер генә Македонский та чыкмаган.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 23 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«ХАФИЗӘЛӘМ ИРКӘМ», «ОЗАТА БАРМА».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Ә. ГАРИПОВА(Әлки р-ны, Иске Салман ав.),
А. ГАРИФУЛЛИН (Биектау),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
Д. НУРГАТИНА (Алексеевский р-ны, Урманасты Шонталасы),
Ф. САБИТОВА (Яшел Үзән р-ны, Күгеш ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Урманасты Шонталасы авылыннан **Дилә НУРГАТИНА!**













Александр АЛЁШИН